РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ
ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«БОЛЬШЕЕЛГИНСКАЯ СРЕДНЯЯ
ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА»
улица Школьная, дом 47, село Большая Елга,
Рыбно-Слободский муниципальный район, РТ, 422640

АТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
«ОЛЫ ЕЛГА УРТА
ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ»
ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ
БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
Мәктәп урамы, 47 нче йорт, Олы Елга авылы,
Балык Бистәсе муниципаль районы, ТР, 422640

Тел./ факс: (8-84361) 2-52-53. E-mail: Sbelg.Rs@edu.tatar.ru

## АТА-АНАЛАР ҖЫЕЛЫШЫ БЕРКЕТМӘСЕ

**22 декабрь 2022 ел** **№2**

Җыелышның рәисе: Миннигалеева Гөлнур Мансуровна

Секретарь: Салахова А.Ф.

Катнашалар: Олы Елга урта мәктәбе укытучылары, Султанова Х.А. - әти-әниләр комитеты рәисе, Фаттахов С. С.- әтиләр советы рәисе, ДПС инспекторы Гафиуллин С., фельдшер Хусаинова Р. Г., 1-11 класс укучыларының әти-әниләре.

## КӨН ТӘРТИБЕ

1. 2022-2023 нче уку елының 1 нче яртыеллыгы нәтиҗәләре (Валеева Э. Р.).
2. Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү тәртибе (Миннитгалеева Г. М.).
3. ОГЭ, ЕГЭ приказлары,норматив докуметлардагы үзгәрешләр белән таныштыру (Валеева Э. Р.).
4. Хокук бозуларны кисәту һәм мәктәптә тәртип торышы (Салахова А. Ф.).
5. Әтиләр советы эшчәнлеге (Фаттахов С. С.)
6. Юлда йөрү кагыйдәләре үтәү – һәрбер кешенең бурычы (ДПС инспекторы Гафиуллин С.).
7. Грипп һәм аннан саклану чаралары (Хусаинова Р. Г.)
8. Яхшы курсәткечләргә ирешкән укучыларның әти-әниләренә рәхмәт хатлары тапшыру.
9. Бәйрәм концерты.

## ҖЫЕЛЫШНЫҢ БАРЫШЫ

Җыелышны мәктәп директоры Миннигалеева Г.М.башлап җибәрде.Ул барлык ата-аналар һәм укытучылар коллективын якынлашып килүче Яңа ел белән тәбрикләде, барысына да саулык-сәламәтлек, зур уңышлар теләде.

Беренче көн тәртибе буенча укыту эшләре буенча директор урынбасары Валеева Э.Р. 1 яртыеллык нәтиҗәләре белән таныштырды, балаларның дәрескә йөрешенә анализ ясады. Шулай ук район күләмендә призлы урын яулаган балаларның исемлеген атады. Балаларның гаилә хәле буенча күп дәрес калдыруларына борчылуын белдерде, әти-әниләргә әлеге проблемага игътибар итүләрен сорады.

Икенче көн тәртибе буенча Миннигалеева Г.М . Яңа ел бәйрәмнәре графигы белән таныштырды. Бәйрәм чаралары вакытында, каникул чорында пиротехника кулланмау, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерде.

Өченче көн тәртибе буенча Валеева Э.Р.бердәм дәүләт имтиханнарына кагылышлы документлар белән таныштырды.ЕГЭ,ОГЭ расписаниесе,аларның дәвамлылыгы,вакыты, 2023 нче елда укучыларның нинди предметлардан имтихан бирү мөмкинлекләре булуы турында тулы мәгълүмат бирде.

Дүртенче көн тәртибе буенча тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Салахова А.Ф тәртип бозуларны кисәтү буенча башкарылган эшләргә күзәтү ясады. Әлеге эшнең мәктәпнең норматив документларына, Уставка, локаль актларга нигезләнеп ашкарылуына басым ясады. “Мәктәп укучыларның һәрберсенә көнкүреш шартларын өйрәнү буенча актлар төзелде, аз керемле гаиләләрдә булган балаларга ярдәм оештырылды,эчке контрольгә алынды. Укучылар, әти-әниләр белән даими әңгәмәләр уздырыла, класс сәгатьләрендә укучыларга тәртип бозуларны кисәтү, наркомания, тәмәке тарту, алкоголизмның зарары турында мәгълүматлар бирелә, профилактик чаралар уздырыла.Бәйрәмнәр чорында шартлаткычларны куллану катгый тыела.Моның өчен ата-аналар җаваплы”. Шулай ук кичке режим үтәлеше һәм укытучылардан кичке дежурлык графигы төзелү турында җиткерелде.

Бишенче көн тәртибе буенча Әтиләр советы рәисе Фаттахов С.С. «Әти сүзе» дигән темага чыгыш ясады.Ул гаиләдә әтинең роле, әтигә хөрмәт, ихтирам кебек кыйммәтләргә басым ясады.

Алтынчы көн тәртибе буенча ДПС инспекторы Гафиуллин С. юл йөру кагыйдәләрен утәү турында чыгыш ясады һәм сорауларга җавап бирде. Экстремизм һәм терроризмга каршы профилактик чаралар турында искәртте.

Җиденче көн тәртибе буенча Олы Елга авылы ФАП фельдшеры Хусаинова Р. Г. Грипп һәм аннан саклану чаралары турында мәгълүмат бирде.

Сигезенче көн тәртибе буенча 1 яртыеллыкны бары тик “4”,”5” ле билгеләренә генә тамамлаган укучыларга рәхмәт белдерелде һәм алар “Рәхмәт хаты”белән бүләкләнде.Ата – аналарга 1-11 класс укучылары тарафыннан әзерләнгән бәйрәм концерты күрсәтелде.

**КАРАР:**

1. Ата–аналарда укытучылар белән берлектә балаларда үзанализ һәм үзконтроль формалаштыруда ярдәм итәргә.
2. Әти-әниләргә балаларның укуларын, дәрескә, ЕГЭ, ГИА га әзерлекләрен ныклы контрольдә тотарга, һәрьяклап ярдәм итәргә; укытучыларга укуда артта калучылар төркеменә кергән балалар белән өстәмә эшләргә.
3. Әти-әниләр белән берлектә тәртип бозуларны кисәтү буенча эшне дәвам итәргә.
4. Кышкы каникул чорында укучыларның кичке режимын ныклы күзәтәү астына алырга.Укытучылар һәм әти әниләрдән кичке рейдлар графигын төзергә һәм үткәрергә.

Җыелышның рәисе: Г. М. Миннигалеева

Секретарь: А.Ф. Салахова